МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.07.2017 Казан ш. № 228

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан һәркем өчен ачык мәгълүматлар, шулай ук аларны танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтлар битләре адреслары турында белешмәләрне алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20.2 статьясы, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан һәркем өчен ачык мәгълүматлар, шулай ук аларны танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтлар битләре адреслары турында белешмәләрне алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А. А. Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2017 елның 17 июлендәге
228 номерлы
боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан һәркем өчен ачык мәгълүматлар, шулай ук аларны танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтлар битләре адреслары турында белешмәләрне алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан һәркем өчен ачык мәгълүматлар, шулай ук аларны танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтлар битләре адреслары турында белешмәләрне алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (алга таба – Тәртип) түбәндәгеләрне билгели:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар (алга таба – граждан) һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт хезмәткәре) тарафыннан “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзләре һәркем өчен ачык мәгълүматлар, шулай ук аларны танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр урнаштырган сайтлар һәм (яки) сайтлар битләре адреслары турында белешмәләр (алга таба – “Интернет” челтәре, Сайтлар турында белешмәләр) тапшыру кагыйдәләрен;

Сайтлар турында белешмәләрне алу һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен.

2. Һәркем өчен ачык мәгълүматлар дигәндә “Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында” 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гомумбилгеле белешмәләр һәм уку-файдалану мөмкинлеге чикләнмәгән башка мәгълүмат аңлашыла. Шул ук вакытта уку-файдалану мөмкинлеге чикләнмәү урнаштырылган мәгълүматны дәүләт хезмәткәренең яки гражданның рөхсәтеннән башка теләсә

нинди даирәгә караган затлар тарафыннан бернинди тоткарлыкларсыз алу һәм үзләре теләгәнчә файдалану мөмкинлеген күз алдында тота.

3. Граждан хезмәткәренең яки гражданның шәхесен танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар буларак түбәндәге барлык белешмәләр яки шуларның берсе каралырга мөмкин: фамилия һәм исем, фотосурәт, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турында белешмәләрне алу һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында белешмәләрне түбәндәгеләр тапшыра:

граждан – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) кергәндә граждан хезмәтенә керү елына кадәрге өч календарь ел өчен;

граждан хезмәткәре – хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, шуңа кадәрге календарь ел өчен.

5. Сайтлар турында белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча (алга таба – Форма) гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла.

6. Әгәр һәркем өчен ачык мәгълүмат граждан хезмәткәренең вазыйфа бурычларын башкару кысаларында урнаштырылган булса, Формада күрсәтелергә тиеш түгел.

7. Тутырылган Форма граждан хезмәткәре яки граждан тарафыннан Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы кадрлар бүлегенең Татарстан Республикасы икътисад министры боерыгы белән Сайтлар турында белешмәләрне эшкәртү өчен җаваплы дип билгеләнгән хезмәткәренә (алга таба – җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат тутырылган Форманың тулылыгын, анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген “Интернет” челтәрен кулланып тикшерә, шәхси имзасын куя, белешмәләрне әлеге Боерыкка Кушымтада каралган форма буенча эшләнгән журналга Форманы кабул итеп алган көндә кертә.

9. Тутырылмаган юллары булган Форма кабул ителергә тиеш түгел.

10. Граждан тарафыннан тапшырылган Формада дөрес булмаган белешмәләрнең булуы ачыкланган очракта, кадрлар бүлеге аны граждан хезмәте вазыйфасына билгеләүдән баш тартуы турында аңа кичекмәстән хәбәр итә.

11. Җаваплы зат Сайтлар турында белешмәләрне граждан хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы”
Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертә.

12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тапшырылган формалар кадрлар бүлегендә биш ел дәвамында саклана, шуннан соң Министрлыкта персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылырга тиеш.

## III. Сайтлар турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – министр) (Татарстан Республикасы икътисад министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат) боерыгы буенча башкарыла.

14. Тикшерү өчен түбәндәгеләр тарафыннан язма рәвештә тапшырылган җитәрлек мәгълүмат нигез була:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

сәяси партияләрнең һәм закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булып тормаган башка гомумроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең даими эшләүче җитәкче органнары;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы зат граждан хезмәткәренә аңа карата тикшерү эше башлану хакында тикшерү уздыру турында боерык чыгарылган көннән алып ике эш көне эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

16. Җаваплы зат граждан хезмәткәре тапшырган Сайтлар турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне аның тарафыннан “Интернет” челтәренә урнаштырылган һәркемгә ачык мәгълүматны эзләү һәм күрсәтелгән мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотлар) ясау юлы белән башкарыла.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү барышында һәм аның нәтиҗәләре буенча язма рәвештә аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

18. Әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына беркетеп куела.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында тупланган мәгълүмат тикшерү уздыру турында боерык чыгарылган көннән алып 10 эш көненнән артык булмаган срокта министрга тапшырыла.

20. Министр тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көн эчендә түбәндәге карар кабул итә:

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын күрү өчен нигезләрнең булмавы турында;

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын күрү турында;

хокук бозу, җинаять, экстремистлык эшчәнлегенә катнашы булу билгеләре булса, тикшерү материалларын дәүләт органнарына аларның компетенцияләренә ярашлы рәвештә җибәрү турында.

21. Җаваплы зат тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәрен тикшерү нәтиҗәләре турындагы боерык белән боерык имзаланган көннән алып ике эш көне эчендә таныштыра.

22. Сайтлар турында белешмәләр тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә хәбәр ителү белән бер үк вакытта, персональ мәгълүматлар һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, тикшерү үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат биргән хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең һәм закон

нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булып тормаган башка гомумроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең даими эшләүче җитәкче органнарына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына министрның язма рөхсәте белән тапшырылырга мөмкин.

23. Тикшерү материаллары тикшерү тәгәлләнгән көннән алып өч ел дәвамында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында белешмәләрне тапшырмаган өчен җаваплылык

24. Граждан, Сайтлар турында белешмәләрне тапшырмаган очракта, граждан хезмәтенә кабул ителә алмый, ә граждан хезмәткәре – граждан хезмәтендә була алмый.

**25.** Граждан хезмәткәре тарафыннан Сайтлар турында белешмәләрнең тапшырылмавы граждан хезмәтеннән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Икътисад министрлыгының
2017 елның 17 июлендәге
228 номерлы
боерыгы белән расланган
тәртипкә
кушымта

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан һәркем өчен ачык мәгълүматлар, шулай ук аларны танып билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтлар битләре адреслары турында
тапшырылган белешмәләрне исәпкә кую
журналы

| № т/б | Форманы тапшыру/кабул итеп алу датасы | Форманы тапшыручының ФИАи | Форманы тапшыручының вазыйфасы (граждан дәгъва итә торган вазыйфа) | Форманы тапшыручының имзасы (яки форма почта аша алынган булса, керү №) | Форманы кабул итеп алган затның ФИАи | Форманы кабул итеп алган затның имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерыкның реквизитлары, тикшерү нәтиҗәләре) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |